“Чишмәкәй” балалар оешмасының

2022-2023 нче уку елы эшчәнлегенә анализ

“Чишмәкәй” балалар оешмасы эшен план нигезендә алып бара. Вожатыйлар үзләренә билгеләнгән классларда шефлык эшен башкара, тәнәфесләрдә кызыклы уеннар оештыралар, тәртип буенча күзәтчелек итәләр.
Укучылар Думасы әгъзалары үткәрелгән һәр чарада укучылар зур оешканлык белән катнашалар.
Балалар оешмасы Сатыш авыл җирлегендә оештырылган чараларда да актив катнашып киләләр. 1 нче октябрь- өлкәнәр көне, 26 ноябрь- Аналар көне, 9 май- Бөек Җиңүгә багышланган, 23 февраль-Ватанны саклаучылар көне, “Нәүрүз” бәйрәменә карата куелган концертларда укучыларыбыз үзләренең талантларын күрсәтеп киләләр. Шулай ук район һәм республика күләмендә үткән конкурсларда да актив катнашалар.
Мәктәптә укучылар 3 оешмага берләшкән: эзтабарлар, варислар оешмасы һәм мәктәп Думасы. Эзтабарлар оешмасында – 42 укучы, Варислар оешмасында- 40, Думада 35 укучы.

Эзтабар һәм варис оешмалары еллык планга нигезләнеп эшләде. Район күләмендә үткәрелә торган ярышларда, акцияләрдә актив катнашып барабыз.

Укучылар Думасы эшчәнлеген спикер Назипова Айзилә Һәм вице спикер Фархуллина Ралинә алып барды. Уку елы башында Думага сайлаулар үткәрелә, комитет җитәкчеләре билгеләнә. Һәр комитет үзенең эш проектын булдырып, Думага тәкъдим итә. Комитет җитәкчеләре үз эшләрен төгәл үтиләр. Аларның тәкъдиме белән бәйрәмнәр, очрашулар, спорт уеннары, күңел ачу кичәләре, рейдлар үткәрелде. Укучылар районның укучылар Думасы белән тыгыз элемтәдә тордылар, район күләмендә оештырылган утырышларда, чараларда ныклы әзерлек белән катнаштылар. “Спорт һәм сәламәтлек комитеты” уку елы дәвамында һәр спорт чарасы үткәрүдә булышлык итте: укучыларны туплау, судьялык эше, нәтиҗәләр билгеләү, класслар арасында мониторинг булдыру – алар эше. “Мәгариф комитеты” җитәкчеләре мәктәп буенча рейдлар үткәрде, китап – дәфтәрләрне тикшерде, сумкалар чисталыгы, формадан йөрү буенча нәтиҗә ясады. “Социаль яклау комитеты” җитәкчеләре инвалид балаларга булышлык күрсәтте, ветеран укытучыларга бәйрәмнәрдә котлаулар өләште, концерт куюда катнаштылар. “Хокук саклау” комитеты да нәтиҗәле эшләде. Бәйрәмнәр, чаралар үткәргәндә тәртип сакчылары булдылар. “Мәдәният комитеты” җитәкчеләре мәктәптә үткән һәр чараны оештыруда булышлык иттеләр,

“Күңелле ял итәбез” проектына нигезләнеп төрле чаралар оештырдылар. Гомумән алганда, Думаның эшчәнлегеннән укучылар үзләре канәгатъ, һәр эшкә теләп алыналар һәм нәтиҗәле эшлиләр.

Мәктәптә укыту процессын сыйныфтан һәм мәктәптән тыш чаралар белән бәйләп алып бару өчен, һәр баланың үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларда укуга булган карашларын уңай якка үзгәртергә тырышып, кызыксындыру тудырып, халкына карата лаеклы варис булу, эшлекле, сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү өчен өзлексез эш алып барылды. Бу юнәлештә “Чишмәкәй” балалар ешмасы, мәктәп балалар думасының эшчәнлегенең роле зур.

Патриотик тәрбия бирүдә сыйныфларда уздырыла торган сыйныф сәгатьләре дә зур әһәмияткә ия. Укучыларда Татарстан республикасы, аның символлары, башкалабыз Казан, районыбыз турында белемнәрен арттыру, Ватанга мәхәббәт, хөрмәт һәм ихтирам, яшь буында милли горурлык, патриотлык хисләре тәрбияләү максатыннан чыгып уздырылган “Изге Болгар иле”, “Татарстан символлары”, “Саба-туган төбәгем”, “Сатыш мәдрәсәсе тарихы”, “Саба районы авыллары”, “Ил тарихы-минем тарих” дигән чаралар моңа ачык мисал булып тора. Тәрбия системасына мәктәп планына нигезләнеп һәр календарь дата кертелгән: ”Белем көне”, “ТР Конституциясе көне”, ”Хәтер көне”, ”Россиянең бәйсезлеге көне”, “ Әниләр көне”, “Ватанны саклаучылар көне”, “Әфганчылар көне”, “Җиңү бәйрәме” һ.б.

Авыл мәктәбендә белем бирү һичшиксез хезмәт тәрбиясе белән бергә үрелеп бара. Мәктәп яны тәҗрибә участогында, суган, кишер, чөгендер һәм чәчәкләр үстерелә, продукция җитештерү һәм аны халыкка тәкъдим итү бүгенге укучы өчен гадәти эш. Укучылар көче белән мәктәп бакчасында яшелчә, җиләк – җимеш үстерелә. Мәктәп территориясе даими җыештырылып экологик рейдлар үткәрелеп килә.

Укучыларны мәктәптән үк һөнәр үзләштерүгә юнәлеш бирү- тәрбия эшенең бер төп максаты. Заманга яраклы һөнәр ияләре җитешмәүдән чыгып, балаларга киләчәк тормыш өчен юнәлеш бирелә. Укучылар белән югары уку йортлары белән танышулар, хезмәт алдынгылары белән әңгәмәләр оештырылды. “Хезмәт” айлыгында авыл җирлегендә яшәүче төрле оста куллы кешеләр белән очрашу үткәрелде.

Әхлак тәрбиясе бирү мәгариф системасында һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Әхлакый тәрбия педагогик теориядә һәм мәктәп эшчәнлегендә иң төп проблема булды һәм ул шулай булып калачак. Әхлакый тәрбия дигәндә, бай рухи сыйфатлар, этик нормалар

булдыру һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен төшендерү максатыннан, яшь буынга системалы тәэсир итүне аңлыйбыз.

Әхлак тәрбиясе процессында укытучыларның роле зур. Алар тиешле шартларны тудыра, эшне оештыра, балаларның укуы, хезмәте, ялы, уены һәм һәртөрле эшчәнлеге дәвамында әхлак мөнәсәбәтләрен тиешле якка юнәлтә. Әхлак тәрбиясе бирүнең төп бурычлары укучы балада әхлак тәҗрибәсе тудырудан гыйбарәт. Әлеге бурычларны тормышка ашыруда бәйрәмнәр, тематик кичәләрнең файдасы зур. Тәрбия сәгатьләрендә җәмәгать урыннарында үз- үзеңне тоту кагыйдәләре, өлкәннәргә хөрмәт күрсәтү, аралашу культурасы, ярдәмләшү, игелек күрсәтү темалары төрле формада яктыртылды. Ел саен мәктәп укучылары көче белән “Чиста авыл” операциясе үткәрелә. Укучылар зиратларны , чишмәләрне чистарту, мәчетләрне юу өмәләрендә актив катнашалар.

Коррупция бүгенге җәмгыятебездәге иң кискен проблемаларның берсе. Ул тормышыбызның бик күп өлкәләренә үтеп керде. Коррупциягә каршы көрәштә бөтен җәмгыятьнең берләшүе таләп ителә. Иң элек һәр кешенең үзаңын үзгәртергә кирәк. Ә яшь буын коррупция белән очрашса нишләргә? Бу зур проблеманы хәл итүгә республика, район күләмендә кабул ителгән максатчан программалар ярдәмгә килә. Ел дәвамында әлеге темага төрле акцияләр, рәсем конкурслары үткәрдек. Республика күләмендә үткәрелгән “Скажем коррупции нет!”, “Надо жить честно!” бәйгеләрендә дә актив катнаштык.

Балаларның сәламәтлеген саклау юнәлешендә “Здоровое питание” буенча эшләдек. Программаның төп максаты - физик яктан камил, сәламәт, шат күңелле яшь буын тәрбияләү, балаларның сәламәтлеген сакларга өйрәтү. Әлеге программаның бурычлары сәламәтләндерү, белем һәм тәрбия бирүнең үзара бәйләнешле булуын күз алдында тотып билгеләнде. Укучыларның һәрьяклап үсешенә, сәламәтлеген ныгытуга, яшь организмны чыныктыруга ярдәм итү; укучыларда физик, әхлакый һәм ихтыяр көче, үзләрен тәртипле тоту күнекмәләре тәрбияләү; сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ булдыру шундыйлардан.

Берничә ел дәвамында укучыларның сәламәтлеген ныгыту юнәлешендә максатчан эш алып барыла. Мәктәптә сәламәтлек көннәре, тематик айлыклар, спорт бәйрәмнәре, медицина хезмәткәрләре белән очрашулар, балалар травматизмын кисәтү буенча дәресләр, спорт түгәрәкләре үткәрүнең балаларның сәламәтлеген ныгытуда уңай нәтиҗәләр бирә. Наркоманиягә каршы көрәш проблемасы бөтен җир шарын биләп алды. Бүгенге яшьләрне бу афәттән саклап калу буенча “Уңышка юл” (“Путь к успеху”) программасы

мәктәптә тормышка ашырыла. Әлеге программа нигезендә укучылар, ата – аналар, укытучылар белән максатчан эш алып барыла. Авыл җирлекләрендә бу проблема белән турыдан – туры очрашкан булмау сәбәпле, ышандырырлык информация тупларга, даими сөйләшүләр алып барырга кирәк. Шунсы сөендерә, ата – аналар бу проблеманы җитди кабул итә һәм программада каралган тематик дәресләрдә, анкета алуда теләп катнаша. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, әлеге программа профилактик яктан отышлы. Укучылар өчен “Имею право знать” видеодәресләр, акцияләр, рәсем конкурслары, сочинениеләр конкурслары, тренинглар оештырылды. 21 ноябрь көнне Халыкара тәмәке тартуга каршы көрәш көне буларак плакатлар, рәсем бәйгесе оештырылды.1 Декабрь – СПИД ка каршы көрәш көнендә фельдшер Зарипова Э.Р. белән профилактик чара үткәрелде. Ата – аналардан, укучылардан анкеталар алынды. “Гомереңне куркыныч астына куйма!” темасына югары һәм урта сыйныф укучылары белән әңгәмәләр оештырылды. Ата – аналар белән очрашуга полиция, балалар эшләре буенча инспектор вәкилләре чакырылды.